Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы "Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы "Ямаширмә гомуми урта белем мәктәбе муниципаль бюджет учреждениесе

авторлыгындагы

**"Без бергә!"** проектына

БӘЯЛӘМӘ.

Мәктәп белән балалар бакчасы белем бирүнең бер үк юнәлештә эшләүче ике чиктәш буыны ул. Әгәр бала мәктәпкә әзерлексез килсә, класста ул үзен уңайсыз хис итә, чөнки балага бөтенләй яңа булган мохиткә күнегергә туры килә. Балалар мәктәпкә ныклы әзерлек белән килсен очен балалар бакчасы һәм мәктәп арасында дәвамчанлык булуы мөһим.

Мәктәп ягыннан караганда дәвамчанлык - балаларның балалар бакчасында алган беренчел белем һәм күнекмәләргә нигезләнеп һәм шул белемнәрне исәпкә алып барыла. Ә балалар бакчасы ягыннан караганда дәвамчанлык ул - мәктәп таләпләренә ориентлашу, мәктәптә белем алуны дәвам итү өчен кирәк булган белем һәм күнекмәләр формалаштыру.

Башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасы арасындагы дәвамчанлык балаларны укырга әзерләү дип кенә кабул ителергә тиеш түгел. Мәктәпкәчә яшьтә бала шәхесенә иң мөһим билгеләр салына. Моның өчен мәктәп һәм бакча арасында бердәм үсеш дөньясы булдыру мөһим.

"Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасы һәм "Ямаширмә урта гомуми белем бирү мәктәбе" төзегән " Без бергә!" проекты балалар бакчасы белән мәктәпнең икетелле белем бирүдә озлексез дәвамчанлыгына нигезләнгән.

**Төп максатлары :** милли ресурс үзәк эшчәнлеге кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга икетелле белем бирү һәм аларны тәрбияләү системасында мәктәпнең әһәмияте.

**Бурычлар:**

- икетелле белем һәм тәрбия бирүдә Федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыру шартларында балалар бакчасы һәм мәктәп арасында дәвамчанлык урнаштыру;
- һәр балага үз мөмкинлекләрен тулаем ачарга булышу;
- балаларны мәктәп белән кызыксындыру, мәктәпкә барасы килү теләген үстерү;
- ФДББС туры китереп, балаларның мәктәпкә әзерлекләрен тәэмин итү;
- бергәләп эшләү формаларын һәм инновацион методларны гамәлгә кертүне дәвам итү;
- тормыш иминлеген, куркынычсызлыгын оештыруның яңа сәламәтлек саклау технологияләрен гамәлгә кертү эшен камилләштерү;
- тәрбияләнүчеләрнең һәм укучыларның туган ягына, халкына, туган теленә, гореф-гадәтләренә, сәнгатенә эмоциональ кыйммәтле карашлары аша милли тәрбия бирү эшен дәвам итү.

Максат һәм бурычларыннан күренгәнчә, “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы һәм мәктәп бербөтен эшчәнлек алып баралар.

Рецензияләнә торган проект кызыклы һәм перспективалы эш булып тора. Балалар , педагоглар, мәктәп укытучылары, эти-әниләр белән эшчәнлек тыгыз элемтәдә алып барыла һәм төрле кызыклы методлар, эш формалары кулланыла. Болар барысы да проектны тормышка ашыру планында тасвирланган һәм әлеге проблеманы хәл итүдә системалы эзлекле алым булып тора.

Проект мәктәп һәм мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирүдә эзлекле хезмәттәшлеккә нигез булып тора.

Казан федераль университеты доценты,
филология фәннәре кандидаты: Г.К.Һадиева

МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ФГАОУ ВО «КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»
ОГРН 1021602841391 ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ
ПОДПИСЬ Һадиева Г.К. заверяю
Документовед